


# Арслан авылы халкы иҗаты

***ТӨЗҮЧЕСЕ ҺӘМ МӨХӘРРИРЕ —***

**ФӘРИТ ГАБДЕРӘХИМ**

***ҖЫЕНТЫКНЫҢ***

***ҖӘМӘГАТЬ ШУРАСЫ:***

**СВЕТЛАНА АЗАМАТОВА**

**РИМА ВӘЛИЕВА**

**ФӘРИТ ГАБДЕРӘХИМ**

**СУФИЯ ГЫЙЛӘҖЕВА**

**ФӘРИТ КОТЫЕВ**

**РӘМИЛӘ ШАФИЕВА**

**Художственное оформление Арсланова Фазита Фаниловича**

**В книге также стихи Факии Халиуллиной, жены первого председателя колхоза**

# Фәрит КОТЫЕВ



Фәрит Шәйхәйдәр улы Котыев 1927 елның 23 июнендә Бүздәк районының Арслан авылында туган. 1939 елда Арслан мәктәбен, 1942 елда Урзайбаш мәктәбен тәмамлый. Дәһшәтле сугыш елларында өлкәннәрнең бөтен йөге хатын-кызлар вә яшүсмерләр җилкәсенә күчә. Фәрит тә колхоз эшенә җигелә: җир тырмата, сабан сөрә, көлтә ташый һәм башка күптөрле эшләр башкара.

1944 елның башында Фәрит Котыевны Магнитогорск шәһәренә ФЗОга җибәрәләр. Укуын бетергәч, металлургия комбинаты тимер юлында эшли. 1953елда туган авылына кайта, Каран МТСында диспетчер вазифасын башкара. МТСЛар бетерелгәч, Арсланда бригадир, хисапчы, бухгалтер, экономист, профсоюз комитеты рәисе, диспетчер булып эшли. Фәрит Котыев, лаеклы ялда булуына карамастан, авыл тормышында актив катнаша: ревкомиссия әгъзасы, авыл Советы депутаты була.

Фәрит Котыев Ватан сугышы елларында тырыш хезмәте өчен медаль белән бүләкләнә, "Хезмәт ветераны", "Атказанган колхозчы" исемнәренә, профессиональ союзларның Башкортстан өлкә советы Президиумының, Бүздәк район хакимиятенең, район гәзите редакциясенең, Арслан авыл Советы һәм туган колхозының Мактау грамоталарына лаек була.

Фәрит Шәйхәйдәр улы һәрвакыт авылның мәдәни тормышы уртасында – төрле кичә-концертларда, фестивальләрдә, тамаша-спектакльләрдә катнаша. Шигърият – Фәрит Котыевның гомерлек юлдашы. Дистәләрчә еллар инде үзенең уй-фикерләрен шигырь юлларына сала, аларны авылдашларына, районташларына җиткерә.

## СИН ЯШИСЕҢ МИНЕМ КҮҢЕЛДӘ

Утыз өч ел сугыш туктаганга,
Утыз өч ел тыныч хезмәттә.
Әле булса сызлый җәрәхәтләр,
Сугыш салган кайгы – йөрәктә.

Төштә күрсәм дә мин сөенәмен,
Өнемдәге кебек сөйләшәм.
Сагынуларым кимегәндәй була,
Синең белән, улым, серләшсәм.

Кайтыр! Кайтыр! Сулмас өмет кенә

Һәр яз саен кабат яңара.
Йөзләремә чыккан сары кебек
Фотоң гына,улым, саргая.

Минем өчен һаман исәнсең син,
Сагынып көтәм сине бүген дә.
Ятып калсаң да сугыш кырында,
Син яшисең минем күңелдә.

**1978.**

## *МӘҢГЕЛЕК УТ*

Мәңгелек ут һәйкәл каршысында,
Корбаннарны барлап яна ул.
Бер карасаң, әйдәп байрак болгый,
Бер карасаң, тынып кала ул.

Мәңгелек ут яна искә төшереп
Кеше ышанмаслык хәлләрне.
Хыялыбыз, туар таңнарыбыз
Җәһәннәмгә чумар мәлләрне.

Сугыш яланында ятып калган
Солдатларның йөрәк уты ул.
Аналарның күңел җылысы ул,
Тыныч тормышыбыз коты ул.

Батырларны данлап янсын мәңге,
Мәңге янсын, берүк сүнмәсен.
Ватанымның күге тыныч булсын,
Сугыш утын кабат күрмәсен.



## ЯЗ

Яз – талантлы рәссам – килү белән,
Матурланды кырлар,урманнар.
Әйтерсең лә, сагынып, сүз куешып,
Яз киләсен көтеп торганнар.

Сандугач та березлексез сайрый,
Моңлы җырын язга калдырган.
Яфраклардан көмеш тамчы тама
Җиргә тансык ләйсән яңгырдан.

Ә чәчәкләр серләшәләр, әнә,
Бал кортларын җыеп акланга.
Яз тиз уза, язның матурлыгы
Күзгә җимешләрдә саклана.

## УКЫТУЧЫМ

Хәтерлисеңме микән, Укытучым,
Көләч йөзле шаян малайны.
Хәйран калып торам: күпме юллар,
Күпме еллар аера араны.

Ә шулай да, тәүге Укытучым,
Син уяткан изге тойгылар
Күңелемә мәңге җуелмаслык
Исемеңне язып куйдылар.

Өстен икән хәтер вакыттан да:
Син һаман да күңелем түрендә.
Ишек ачылыр да шат елмаеп
Килеп керерсең күк бүген дә.

Чиксез, серле белем дөньясына
Алып кердең тотып кулымнан.
Биргән ачкычларың белән ачтым
Йозакларны тормыш юлымда.

## КАЗ ӨМӘСЕ

Бүген бездә, дуслар, каз өмәсе–
Көттермичә килеп җитегез.
Казларыбыз бигрәк уңды быел,
Каз итеннән авыз итегез.

Каз өмәсе татар авылында–
Борынгыдан калган йоладыр.
Өмәләрдә күңел ачсаң гына,
Озак онтылмаслык буладыр.

Гармуныңны, егет, онта күрмә,
Күрегенә моңнар салып кил.
Көйләреңнең безнең үзәкләрне
Өзә торганнарын алып кил.

Өлкәннәр дә кайтсын яшьлегенә,
Биесеннәр, әйдә, туйганчы.
Читек табаннарын туздырганчы,
Тәмам күңелләре булганчы.

Бүген бездә–бәйрәм, каз өмәсе,
Җырлагыз да, дуслар, биегез.
Бии-бии талсын аягыгыз,
Җырлый-җырлый талсын телегез.

## САБАН ТУЕ

Бу бәйрәмне һәркем көтеп ала–
Яшьләр генә түгел, картлар да.
Бер урында басып тора алмый–
Чабышкыны көтә атлар да.

Сабан туе–игенчеләр туе,
Җиргә гашыйкларның бәйрәме.
Тырыш хезмәтебез тантанасы,
Авыл тормышының зур яме.

Уйна әле, дустым, гармуныңны,
Дәртлеләре төшсен биергә.
Авылдашлар, эштә генә түгел,
Туйларда да булыйк гел бергә.

Көрәшчеләр, әйдә, көч сынашсын,
Көчлеләре герен күтәрсен.
Их, егетләр, әнә, кызлар бии,
Йөрәкләргә баса үкчәсе.

Әбиләр дә читтә калмаганнар,
Француз яулыкларын ябынып,
Яшьләр белән бергә биеп йөри,
Үткән яшьлекләрен сагынып.

Сабан туе, өмәләре белән
Гасырларга киткән тамырлар.
Эшчән халкым, тамырларга карап
Туар чорлар безне танырлар.

## ИКМӘК

Күкрәгемә куеп икмәк телəм,
Күпереп пешкән авыл икмәген.
Авылым! Хәтта иген икмәүчене
Икмәгеңнән мәхрүм итмәдең.

Хуҗабикә, зурлап, иң беренче
Икмәк куя табын түренә.
Өстәлләрдә нигъмәт күп булса да,
Башлап кеше сиңа үрелә.

Бу дөньяда баш син барына да.
Син булганга ямьле көзебез.
Син булганга сүнми өметебез.
Син булганга–якты йөзебез.

## Я, ӘЙТ ИНДЕ...

Җан сөйгәнем булдың гомерлеккә,
Сөешеп кавышканнар бик сирәк.
Теләкләрең кабул булды, бугай,
Я әйт инде, тагын ни кирәк?

Тормыш юлын бергә тату үттек,
Сизелмичә узды күп еллар.
Бик-бик иртә өзелмәсен иде
Киләчәккә барыр ак юллар.

Яшьлегемне күрәм улларымда,
Кызларымны сиңа охшатам.
Алар белән барысын уртаклашам,
Алар белән эчем бушатам.

"Гомер буе сине яраттым",–дип
Чын йөрәктән әйткән сүзеңә
Дөньядагы барлык гүзәллекне
Бүләк итәр идем үзеңә.

Күзләреңә карап әйтә алам,
Синең өчен тибә бу йөрәк.
Соңгы сулышым да сиңа гына,
Я, әйт, җаным, тагын ни кирәк?!

## АТЛАР ЗАРЫ

Җыелганнар атлар. Тикшерәләр
Кемнең нинди эшләр "кырганын",
Ат халкының ничек көн күргәнен,
Алда нинди эшләр торганын.

Кара алаша әйтте чыгышында:
“Эшкә катнашырга кирәк,–ди–
Соңгы елда атка почет бетте,
Эшкә әйтү нигә сирәк,–ди.–

Бигрәк бозылдылар яшь бияләр,
Гыйшык–мыйшык уйнап аздылар.
Бөтереләләр айгыр тирәсендә,
Оят кирәктер бит аз гына.

Йөгән кими сигез яшькә җитте
Арабызда инде ничә ат.
Ошбу хакта ачынып хәбәр иттем
Бригадирга барып ничә кат.

Ир-егетләр безнең белән бергә
Максатларга барып җиткәннәр.
Өч яшьтән үк йөгән кигезгәннәр,
Тәрбияләп эшкә җиккәннәр.

Тормыш арбалары ватык ята,
Тик тоталар безне абзарда.
Без атларга кемнәр ярдәм итәр,
Шикаятьне кемгә язарга?!”

## ИКЕ МАШИНА

Икесе дә бер заводта туган,
Очраштылар ике ел үткәч.
Дөнья мәшәкатен байтак татып,
Чакрым йомгакларын күп сүткәч.

Беренчесе директорны йөртә,
Икенчесе–колхоз эшендә.
Берсе–кызлар кебек чиста-пөхтә,
Икенчесен күрмә төшеңдә!

Шәһәр машинасы хәлен сөйли,
Йөргән юлы белән мактана.
Авыл юлын бер дә күрмәгәнгә
Сабый бала кебек шатлана.

Колхоз машинасы тыңлады да
Мактануга тартым сүзләрне
Бер йөз грамм "Корвалол"ын эчте,
Сөртә-сөртә яшьле күзләрен.

"Күрсәтмәсен,–диде,–мин күргәнне,
Бигрәк бәхетсезләр булганмын,
Иртә яздан кара көзгә кадәр
Пычрак ярыр өчен туганмын.

Язын-көзен хәлем ифрат мөшкел,
Тракторга килеп тагылам.
Кышкы бураннарда бульдозерга
Тезләнепләр генә ялынам.

Тагын бер ел шулай михнәт чиксәм,
Пенсиягә, бәлки, чыгармын.
Яшь көенә бабай булып беттем,
Гарьлегенә ничек чыдармын".

## АРАКЫ

Газраил әйткән аракыга:
"Җитте сиңа, җаның алам,–дип–
Баштан ашты синең гөнаһларың,
Хәзер сиңа урын табам,–дип.–

Күпме язмышларны харап иттең,
Агуладың яшен, картын да.
Ятимнәрнең күпме яшен түктең,
Ләгънәт озата сине артыңнан.

Синнән килә дөньядагы бөтен
Бәхетсезлек, бөтен яманлык.
Моның өчен сине әллә кайчан
Җәһәннәмгә тотып ябарлык.


Сабыйларның нинди гөнаһы бар?
Тумас борын гарип итәсең.
Гел Газраил диләр, җегетләрнең
Башларына син бит җитәсең".

Ә аракы әйтте: "Берәүне дә
Кыстаган юк, мине ал!–диеп.
Көткән дөньяң асты өскә килсен,
Җаның теләгәнчә сал!–диеп.

Үзләре бит ачып бокалларга
Теләк тели-тели салалар.
Күзләр акайганчы эчәләр дә
Башларына кайгы алалар.

Телем дә юк минем, кулым да юк,
Савытымда ятам тын гына.
Җанымны алма, яман данымны ал,
Үтенечем сиңа шул гына.

Галиҗәнаб, нигә япсарасың
Башкаларның миңа хатасын.
Шешә эчләрендә мин булып–син,
Син, Газраил, үзең ятасың."



# ФӘРИТ ГАБДЕРӘХИМ



Фәрит Ибраһим улы Габдерәхим 1933 елның 8 гыйнварында Бүздәк районының Арслан авылында туган. 1955 елда Октябрский нефть техникумын, аннары Башкортстан дәүләт университетының татар–урыс бүлеген тәмамлаган. Бераз балалар укыта. 1965–69 елларда Туймазы шәһәренең "Ленин юлы" редакциясендә эшли. 1969 елны республиканың "Кызыл таң" гәзите редакциясенә эшкә чакырып алына. 1994 елның ноябренә кадәр әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли. Хәзерге вакытта иҗат белән шөгыльләнә.

Фәрит Габдерәхимнең "Йөрәк уты", "Җирдәге йолдызлар","Анкетага кермәгән юллар", "Алтын туй", "Күңел күзе", "Гашыйклар, сезгә генә", "Кичер мине!" дигән китаплары Башкортстан китап нәшриятында дөнья күрделәр. Нәшриятка "Синең белән мин" дигән шигырьләр һәм поэмалар җыентыгын әзерләп тапшырды. Ул Русия язучылар берлеге һәм Башкортстан татар язучылары берлеге, Башкортстан журналистлар берлеге әгъзасы, Башкортстанның атказанган мәдәният

# РУХИ МИРАС

Татар авыллары эчке вә тышкы күренешләре белән бер-берсенә охшаганнар. Хәлбуки,һәр авылның үзенә хас тарихы, үсеш юлы, рухи биографиясе башкалардан азмыкүпме аерылып торган яклары да була. Туган авылыбыз Арсланга да хас бу.

Арслан кешеләре кырысрак холыклы булсалар да, гаделсезлекне, икейөзлелекне яратмыйлар, җыр-моңның, тапкыр сүзнең, гомумән, әдәби иҗатның кадерен беләләр. Хәтта үзләре дә шигырь, бәет, җыр-көй, такмак, экиятләр чыгаралар...

Бу җыентыкка авылдашларыбызның берникадәр иҗат җимешләре тупланды. Рухи мирасыбыз мондагы язмалар белән генә чикләнми, әлбәттә. Аларны һаман, һаман барларга, җыеп халыкның үзенә кайтарырга ишәйтә барырга кирәк. Авылыбызның киләчәктәге яшь сәләтләре рухи мирасыбызга үз өлешләрен кертер дип өметләнәбез.

**Җыентыкның җәмәгать шурасы әгъзалары.**

Тавышыңны ишетсеннәр,
Бер җырлап җибәр әле.
Бер күрүдә гашыйк итә
Арслан чибәрләре.

Бул син егет, булма җебек,
Яратмыйм җебекләрне.
Төнлә төшләремә керә
Арслан егетләре.

Төшеп калганнардан түгел,
Без Арслан бит әле.
Безнең белән сөйләшергә
Права иметь ит әле.

Арсланның татары,
Чабатаңны сат әле.
Күмәч китереп бирерләр,
Мич башында ят әле.

Ай, силсәвит, вай силсәвит,
Суган суың сатсана.
Суган суың сатмасана,
Суга сусатмасана.

Чәчкәле иртәбез дә,
Чәчкәле кичебез дә.
Баш аркылы очырырбыз,
Арыслан көче бездә.

Алкалары да көмеш,
Беләзеге дә көмеш.
Арслан кызын яратсаң,
Йокылар кача, имеш.

Без кимибез итек-читек,
Без киябез чабата.
Колхоз эшенә барганда
Чабата шәп атлата.

Агыйделдән агып килә
Кәлҗәмә кабыклары.
Тышы кылка, эче шулпа
СССР халыклары.

И, әйкәем, кара әле,
Лейтенант үтеп бара.
Лейтенантта да кайгы юк:
Кәлҗәмә бетеп бара.

Башымны да кыралар,
Күтемне дә кыралар.
Колхоз ашарга бирмәгәч,
Минем белән торалар.

Әйдә, җаным, алып барам
Корбанай урманына.
Машиналар батып ята
Арслан урамында.

И кыр казы, кыр казы,
Нигә кайтмадың язын?
Юллар такыр булыр иде,
Булса безнең ком базы.

Көдрәймәгез көл туздырып,
Бездә бар утлы күмер.
Куркытмагыз–курыкмыйбыз,
Куркаклар давно умер.

Что такой, безобразие!
Кияү чыкмый кызларга.
Ислам бабай чиләк ясый
Карт кызларны тозларга.

Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Әтәче күкәй салмый.
Өч хатын алып аерган,
Һаман да кызлар сайлый.

Әстәгафирулла тәүбә,
Әтәчтән кача тавык,
Кеше көлдереп йөремә
Кәзә сакалы тагып.

Алай да сиңа ярый,
Болай да сиңа ярый.
Әберәкәй сандугачы
Синнән моңлырак сайрый.

Түбәң тишек , ярык ишек,–
Ата ялкау, ыстырам.
Кәләшеңне онытырсың,
Ботарама кыстырсам.

Чәчүргече, чәчүргече,
Чәчүргече шелковой.
Чикләвек тә вата алмый,
Бабайга кызлар давай.

Качмас әле колхоз эше,
Төшик әле инешкә.
Аракысы булмаганда
Ярап тора көмешкә.

"Турҗы тавы" биек түгел,
"Турҗы тавы" тәбәнәк.
Маһисәрвәр алкаш ирен
Алып кайткан тәпәләп.

"Песи күпере"–шәп күпер,
Песиен күргәнем юк.
Өр, дускаем! Синең чаклы
Этнең дә өргәне юк.

И җаныем, туның тузгач,
Әйләндереп киярсең.
Атлауларың бигрәк матур,
Ана үрдәк диярсең.

"Ике күпер"–зур күпер,
Икесе дә юк күпер.
"Ике күпер" асларында,
Җаныкаем, бер үптер.

Нигә күзләрең майланган,
Аракы эчтең мәллә;
Нигә шаркылдап көләсең,
Иреңне печтең мәллә.

"Көймә тау"ның башларына
Күкәй салган саескан.
Аракы дип эчкән идем,
Инеш суы саеккан.

**(Фәрит Габдерәхимнең хәтер дәфтәреннән).**



# ЗӘБИР КОТЫЕВ

Зәбир Рифгать улы Котыев 1969 елның 3 ноябрендә Бүздәк районының Арслан авылында туган. 1987 елда Арслан урта мәктәбен тәмамлаган. 1987–89 елларда армиядә, шул исәптән Әфганстанда хезмәт итә, медаль белән бүләкләнә.

Армиядән кайткач, Туймазы фарфор заводында эшли. 1990 елда өйләнә, ике улы туа. 1991 елда туган колхозына кайтып эшли башлый. 1996 елда токка сугылып үлә.

Зәбир шигъри җанлы егет була. Уй-фикерләрен шигырь юлларына салырга омтыла.

## ИКЕ ТӨС

Тормышымда калды тик ике төс,
Берсе ап-ак, аяз көн сыман.
Икенчесе аның–кайгы төсе,
Кап-караңгы көзге төн сыман.

Ике төснең
уртасында ятам—
Яшәү белән үлем
чигендә.
Мине упкын
тартып алмак
була,
Кара җиргә батып
чигенәм.
Шул төш белән
китәм уянып,
Төннәр буе ятам
уйланып...

**5.02.90.**



❖❖❖

Мине тәмам әсир
иттең бугай,
Сиңа гына бары
табынам.
Киткәнеңә ике
сәгать тә юк
Сине, Гөлнур,
өзелеп сагынам.

Сине көткән чакта минутлар да
Еллар кебек озын тоела.
Йомшак булсын килер сукмагы дип,
Агачлардан яфрак коела.

Ә син килеп кергәч палатага
Кояш чыккан сыман яктыра.
Беләсеңме, иркәм, ак хыяллар
Икебезне бергә чакыра.

❖❖❖

Күпме бәла китерәбез
Әнкәйләрнең башына.
Азак яшь түгәбез, башны
Бәреп кабер ташына.

Әнкәйләргә зур-зур рәхмәт
Әйтеп каласы иде.
Әнкәйләрнең бәхиллеген
Бер чак аласы иде.

# ФАТЫЙМА АСКАРОВА



Фатыйма Сәләм кызы Аскарова 1926 елның 1 июнендә Бүздәк районының Богады авылында туган.

Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, унсигез яшьлек Фатыйма 1944–46 елларда Бүздәк районының Таулар, Урзайбаш мәктәпләрендә укыта. 1947 елда Башкортстан дәүләт педагогия институтына укырга керә һәм 1951 елда, аны уңышлы тәмамлап, урта мәктәп укытучысы дигән исем алып чыга.

Фатыйма Сәләм кызы Арслан авылы мәктәбендә озак еллар дәвамында балаларга туган тел һәм әдәбияттан сабак бирде.

Бөек Ватан сугышы елларында тырыш хезмәте өчен һәм В.И.Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән медальләр белән бүләкләнә. Утыз биш ел буе яшь буынга белем һәм тәрбия биргән өчен "Хезмәт ветераны" исеменә лаек була. 1996 елның 7 июлендә Фатыйма Сәләм кызы Аскарова фани дөньядан бакый дөньяга күчте.

## АПАМ

Тук-тук! Тук-тук!
Кем ул бимазалый?
Сикереп тордым–энекәш килгән.
Йөрәккәе ничек күтәргәндер–
Бик-бик авыр хәбәр китергән.

Кая барыйк–туган йортка кайттык,
Гаҗизлектән нишлик, уф, Алла!
Йөрәкләрне кысып учыбызга,
Юлга чыгып киттек–Уфага.

Авыруыңны, апам, ишетсәм дә,
Әҗәл килер дип уйламадым.
Кичер, апам! Синең сүзләреңне
Тыңламаган чак булгалады.

Майның егерме өче. Без Уфада.
Бар табигать кабат яшәргән.
Умырзая кебек иртә сулдың,
Өлгерәлми калдың яшәргә.

Шундый чибәр иде минем апам,
Шундый көләч, шундый сөйкемле,
Май аеның гөлләр бакчасында
Яңа аткан чәчәк шикелле.

Кара гүргә керде газиз апам,
Бир, ходаем, үзең түземлек.

Уфа зиратында күңелемнең
Иң-иң нәфис кылы өзелде.

Апам-бәгърем, олы җанлы идең,
Берчакта да безне какмадың.
Бала чакта усал маэмайлардан,
Усал малайлардан якладың.

Башкайларны ташка бәрергәме,
Шыңшып исә хәтта җилләр дә.
Төштә генә сине була күреп,
Киттең, апам, кайтмас җирләргә.

Һәр яз саен кошлар урап кайтыр,
Һәр яз саен дөнья яшәрер.
Син кайтмассың...
Соңгы көнемәчә
Сине сагынып, апам, яшәрмен.

1947.

# Уйимак фикерлар

❖ Кеше үлемсез булса, дөньяның кадере булмас иде.
❖ Безсез дә бит Алла яши ала, без Алласыз яши алмыйбыз.
❖ Инәкәң кичермәгән гөнаһны Алла да кичермәс.
❖ Телеңә хыянәт–инәкәңә хыянәт.
❖ Үз эшен белә хәмер, дәртләнеп казый кабер.
❖ Кара төндә Ай да Кояш булып күренә.
❖ Горур җаннар көлә–елап җибәрмәс өчен.
❖ Акыллылар гына акылдан яза.
❖ Кесәң тулы булу белән мени ул, башың буш булгач.
❖ Тик эчәргә булсын исерекбашка–җеназа да, туй да бер аңа.
❖ Яшь чакта барысы да шигырь яза, ә олыгайгач–шагыйрьләр генә.
❖ Иблискә хезмәт итүче талантлы булса, ул иблистән дә куркынычрак.
❖ Ире эчкән хатынның башы авыртучан.
❖ Алтынны алтынга манмыйлар.
❖ Ул КПССтан чыккан,ә КПСС аңардан чыкмаган.
❖ Күршең бай булсын: күршең бай булса, ул синекенә тими.
❖ Тарих тәгәрмәче астында калып имгәнгән кешеләрне кем дәвалар?!
❖ Сөю учагына утынны гел өстәп торырга кирәк.
❖ Аны яратмыйлар–хаталанмаган өчен.
❖ Тозсыз кеше, күпме генә тоз ашаса да,

тозсыз булып кала.

❖ Кешеләрсез Алла барыбер Алла булып кала, ә Алласыз кешеләр шайтанга әйләнә.

❖ Туган төяк-ышанычлы терәк.

❖ Өлкәннәрне хөрмәтләсәң, үзеңне дә хөрмәт итәрләр.

❖ Кешеләр арасында яшәп тә, ялгызлык газабы кичерергә мөмкин.

❖ Сукырлар да төш күрә.

❖ "Йомычка күпере"ндә йомычка буламыни?!

❖ "Ур"ны урап үтмәсәң дә, бурны урап үт.

❖ "Ур" чокырына төшсәң дә, хур чокырына төшмә.

❖ Авылың-Арслан, ә үзең-куян.

❖ Ишкәкләр булды, хәзер "Көймә-тау"ның көймәсен табасы гына калды.

❖ Халык хәтеренә язылган сүзләр генә җуелмый.

❖ Китап янганда дөнья җылынмый, ә суына.

❖ Дөньяда ике көч бар: берсе-атом, икенчесе-хатын.

❖ Сулары тәмсез булса да, туган җир булмый ямьсез.

❖ Манарасыз татар үзен сатар.

❖ Сүз ирегеге булмаган җәмгыять эчтән таркала.

❖ Бабайның да, малайның да күз яше тозлы була.

❖ Дошманыңны каргама, бәддога укыма, син аның яңа йорт салуын гына телә.

❖ Машинаң булу белән мени ул-анда әниеңә

урын табылмагач.

- Арсланның ике мәчете булмаган тәкъдирдә, балалар кайда укыр иде икән?!
- “Ком базы” юлына комның тәтемәве дә ихтимал.
- “Песи күпере” этләрне дә үткәрә.
- Этне ияртмә, ияртсәң–сукма!



Арсланов Фәзит эше.

# Бәетләр

## ФӘРИТ ГАБДЕРӘХИМ
## САК–СОК

(Бәетнең яңа варианты)

Империядә йозаклы ишек,
Сак-Сокның яңа бәетен ишет.

Ничәмә гасыр сөйлиләр юкны:
Ике малай дип Сак белән Сокны.

Бергә яшәдек ике дус халык,
Кодалар булып, кыз биреп–алып.

Бергәләп чәчтек, бергәләп урдык,
Бергәләп сүттек, бергәләп кордык.

Кемнәр алганнар мөлкәт-байлыкны,
Сак-Сок иттеләр ике халыкны.

Империядә таңнар караңгы,
Сак белән Сокның бәгъре яралы.

Кайсы яккадыр дөнья авыша,
Ике дус халык алмый кавыша.

Ике тарафта Сак-Сок тавышы,
Сак-Сок тавышы бигрәк сагышлы.

Ике дус халык бергә яшәде,
Сак белән Сокның агыла яшьләре.

ке арага дивар корганнар,
агындырадыр бергә торганнар.

Дуслык канатын кемнәр каерган,
Кайсы залимнәр безне аерган.

Кара урманда мылтык коралар,
Каушыр көн тугач, ызгыштыралар.

Империянең ач каракошы,
Кемнәргә төшәр Сак-Сок каргышы.

Империядә җилләр исәдер,
Кавышу юлларын кемнәр кисәдер.

Яңгыр явадыр Сак-Сок башына,
Еғълап барырга кемнең каршына.

Калган киемне кемнәр киярләр,
Ике дус халык иде, диярләр.

Нинди әфсеннәр коткарыр безне,
Кабат халыкка әйләнербезме?!

## СУФИЯ ГЫЙЛАҖЕВА

Суфия Ризван кызы Гыйлаҗева 1953 елның 16 октябренда Бүздәк районының Яңа Әмир авылында туган. 1969 елда сигезьеллык мәктәпне тәмамлый, Колхозда төрле эштә эшли. Бухгалтерлар мәктәбен тәмамлый. 1972 елда

Арслан авылына килен булып төшә. Дүрт бала үстерә. Озак еллар дәвамында колхозда савучы булып эшли.

Шигърияткә кечкенәдән үк тартыла. Этисе Ризван шигырь укырга ярата, ә нәни Суфия аларны шунда ук ятлап ала. Аның этисе дә шигырьләр яза. Аның йогынтысында Суфия да шигырь чыгара башлый. "Муса Җәлил" исемле шигырен дүртенче сыйныфта укыганда язган. Шуннан бирле шигърият–аның гомерлек юлдашы. Ул аеруча бәет чыгарырга һәвәс.

---

## ГӨЛНАРА БӘЕТЕ

Туксан беренче елның
май аенда авылыбыз тирән
кайгы кичерде.Унсигез яшьлек
бик чибәр кыз Гөлнара вафат
булды. Улым Рөстәмнең сыйныфташы
иде.

Май таңнары бигрәк матур була,
Өздереп лә сайрый сандугач.
Исән булсам, шушы кошлар моңын
Тыңлар идем һәрчак таң тугач.

Тик нигәдер гомерем кыска булды,
Бик-бик иртә йомдым күземне.
Май аенда тудым бу дөньяга,
Май аенда гомерем өзелде.

Мин омтылдым зәңгәр киңлекләргә,
Гашыйк булдым тургай җырына.
Бүз тургайлар быел үксеп елап
Озаттылар соңгы юлыма.

Шатлангансың, әнкәй, мине тапкач,
Апасына иптәш булды, дип.
Эч серләрен бергә бүлешерләр,
Бер-берсенә терәк булды, дип.

Гүзәл апам, миңа үпкәләмә,
Сиңа сердәш була алмадым.
Бик-бик теләсәм дә мин яшәргә,
Явыз авыру арттан калмады.

Абыйларым, мине онытмагыз,
Мин бит сезнең иркә сеңелегез.
Яшәү тәмен татып бетәлмичә,
Үсеп җиткәч сулган гөлегез.

Әнкәем, мин гөл ярата идем,
Корытма син бакча гөлләрен.
Беләм, сиңа бигрәк авыр хәзер,
Сагыш белән үтәр көннәрең.

Бик елыйсың килсә, чык бакчага,
Шифа нурын сибеп таң атар.
Көмеш чәчләреңне җилләр сыйпар,
Гөл-чәчәкләр кайгың таратыр.

Әй, әтием, сиңа да бик авыр
Мәңгелеккә мине югалту.
Җаны илергәнне мөмкинме соң
Җылы сүзләр белән юату?!

Сабакташ Рим, Рөстәм, Илфат, Наил,
Һәр яз саен миңа килегез.
Кабереме гөлләр утыртыгыз,
Яшәү кадерләрен белегез.

Назлы гөлләр кебек аз яшәдем,
Бик тиз сулдым умырзаядай.
Чәчкә кебек балкып яшәдем дә
Чәчкә килеш киттем дөньядан.

## РӘЗИЛ БӘЕТЕ

Һаваларны иңләп очар өчен
Кошларда да була пар канат.
Пар канатның берсе зәгыйфьләнсә,
Оча алмый инде ул кабат.

Зәңгәр күлдә пар аккошлар йөзә,
Бер-беренә назлы сыена.
Иркәләнеп шаян дулкыннарга,
Кояш нурларына коена.

Пар аккошлар кебек яшәр чакта,
Усал язмыш безне аерды.
Җиһаннарга күтәрелер чакта,

Канатларны давыл каерды.

Җибәрәлмим кайнар сәламемне,
Сагынсам да сине өзелеп.
Бигрәк яшьли ялгыз торып калдың,
Раушаниям бәгърем, түз инде.

Мин теләмим синең сулганыңны,
Чәчкә аткан нәфис гөл бит син.
Аяз төндә җиргә нурлар сипкән
Якты йолдызларга тиң бит син.

Син әле яшь, бәлки йөрәгеңдә
Сөю хисе кабат кабыныр.
Тик улыма әти булмас инде,
Үз әттәсен өзелеп сагыныр.

Язлар җиткәч, кошлар кабат кайтыр.,
Тирәкләрдә канат кагыныр.
Тик мин генә кабат кайта алмам,
Туганнарым мине сагыныр.

Хатлар язар җирдә түгелмен шул,
Әҗәл кисте кайтыр юлымны.
Туганнарым, сезгә ышанамын,
Ташламассыз минем улымны.

### АЗАТ БӘЕТЕ

Күзге төннең кара кочагында
Аһ!-иттеләр зифа каеннар.

Зур тигезлектә очты мотоцикл,
Ак каеннар тетрәп калдылар.

Бөгелсә дә кара кайгыдан,
Әйтәлмиләр хәсрәт сүзләрен.
Авылымның бөркет кебек улы
Мәңгелеккә йомды күзләрен.

Яп-якты бер йолдыз атылды,
Кара күктә якты юл ярып.
Япь-яшь гомер җирдә өзелде,
Йөрәкләргә сүнмәс ут салып.

Көн дә иртән шушы борылышта
Каеннарым калды озатып.
Салават дус! Бүген соңгы тапкыр
Эшкә озаттың мине уятып.

Ниндидер бер авыр йокы басып,
Торалмыйча яттым урыннан.
"Китмә!" дигән искәртүле аваз
Ишетелде йөрәк түремнән.

Йөрәк тавышына колак салу
Кая инде безнең заманда.
Дөнья эшен бетермәкче булып,
Ашкынабыз һаман, һаман да.

Газраилнең кара канатлары
Баскан булган ике иңемә.

Сау бул!–диеп хәтта әйтәлмәдем
Рәмиләмә, назлы гөлемә.

Рәмиләкәй бәгърем, кичер мине,
Син яшәргә тиеш, яшәргә,
Хозур күлдәй матур күзкәйләрең
Манчылгандыр кайнар яшьләргә.

Сиңа әйтәсе җылы сүзләремне
Үзем белән алдым кабергә.
Бер-беребезне чиксез яратсак та,
Аерылдык инде мәңгегә.

Бергә алган матур күлмәгеңне
Бәйрәмнәрдә генә киярсең.
Киярсең дә, мине искә алып,
Азатымның төсе диярсең.

Киткән чакта нигә кызларымның
Алсу биткәйләрен үпмәдем?!
Кичерегез мине, бу дөньядан
Үз теләгем белән китмәдем.

## ЗӘБИР БӘЕТЕ

Кеше гомере кыска һәм кадерле,
Ничек кенә авыр узмасын.
Үткән гомер өчен оялырлык,
Үкенерлек кенә булмасын.

Әфганнарга барып, яуга кергәч,
Яшәү тәмен ныграк аңладым.
Бик ашкынып кайттым туган җиргә,
Тик туйганчы яши алмадым.

Ата-анама булган мәхәббәтне
Йөрәгемдә һәрчак йөреттем.
Унҗидесе тулган гүзәл гөлне–
Гөлнурымны сөйгән яр иттем.

Яшәр кебек идек мәңге бергә,
Күгәрченнәр кебек гөрләшеп.
Каршыларбыз кебек һәрбер таңны
Пар сандугач кебек серләшеп.

Лачын кебек сау-сәламәт уллар
Бүләк итте миңа Гөлнурым.
Сөеп туя алмадым мин аларны,
Төсем итеп сезгә калдырдым.

Миңа дигән йөрәк назларыңны
Улларыма минем бир, әнкәй.
Мине сагынып сызса йөрәккәең,
Улларымны кат-кат үп, әнкәй.

И ашкынды йөрәк, сизмәгәндер
Соңгы җәйләренең җитәсен.
Белмәдем шул барлык туганнарны
Янган утка салып китәсем.

Иске өйне сүтеп, урынына
Без ясадык бергә түтәлләр.
Явыз үлем керде арабызга,
Аерылмасын иде бүтәннәр.

Эчең пошса, әнкәй, чык бакчага
Таң җиленә сөйлә сереңне.
Әнкәй бәгърем, берүк читкә типмә
Гөлнурымны, иркә гөлемне.

Соңгы тапкыр өйдән чыккан чакта
Карамадым ник соң борылып.
Әй әнкәем, нурлы йөзләреңне
Бик карыйсым калган уелып.

Машинада минем яннан гына
Кулын болгап үтте Гөлнурым.
–Төшке ашка кәтәм, кайт, яме,–дип
Елмайды да китте күз нурым.

Кем уйлаган аның нурлы йөзен
Соңгы тапкыр диеп күрермен.
Белмәдем шул туган йортка кабат
Үле гәүдәм генә керерен.

Сагынсам да хәзер кайта алмыйм
Бикле инде кайтыр юлларым.
Әткәй, әнкәй, Гөлнур, туганнарым,
Хушыгыз,хуш, газиз улларым!

## ЭЛЬМИРА БӘЕТЕ

Җир йөзенә ямьле язлар килеп,
Күмелгәндә дөнья нурларга
Синең белән икәү без кавыштык,
Бәхет кошын тотып кулларга.

Без теләдек тормыш сукмагыннан
Җитәкләшеп атлап барырга.
Бер үк төптән үскән куш каендай,
Гомер буе бергә булырга.

Тик теләкләр кабул булалмады,
Ташлап киттең мине калдырып.
Көннәр-төннәр өзелеп көттем сине,
Яшьле күзләремне талдырып.

Сагынуларым, сары чәчәк булып,
Юлларыңа синең сибелде.
Күз яшьләрем, көмеш тамчы булып,
Иңнәренә синең түгелде.

Тәүге балабызны көткән чакта,
Шатлыгыбыз уртак булмады.
Сабыемның йөрәк тибешләрен
Ялгыз гына әрнеп тыңладым.

Хәзер инде миңа үпкәләмә,
Сабыемны алам яныма.
Салкын гүрләр мине өшетмиләр,

Йөрәк парәм булгач янымда.

Ни үкенеч, газиз күз нурымның,
Алсу йөзен күрә алмадым.
Икебезнең гомер бергә сүнде,
Сабыемны сөя алмадым.

Җырлый-җырлый бишек тирбәткәндә
Аналарның йөзе нур булыр.
Бишек күрсә, газиз әнкәемнең
Күзләренә кайнар яшь тулыр.

Түз, әнием, түкмә яшьләреңне,
Ике гомер безгә бирелми.
Чәчкә аттым, җимеш бирәлмәдем,
Кырау сукса, гөл дә терелми.

Гәүдәм булса салкын җир астында,
Рухым ашар зәңгәр күкләргә.
Ак күбәлек булып мин кайтырмын,
Җиргә ямьле җәйләр җиткәндә.

Очкан чакта талса канатларым,
Хәл җыярмын кунып талларга.
Сагынсагыз, назлы җилләр булып,
Мин исәрмен җәйге таңнарда.

Якты кояш кебек, ак күлмәктән
Аяк бастым сезнең авылга.
Нурлы йөзле, саф йөрәкле булып,

Калсам иде сезгә һаман да.

Ир-егетләр, сезгә киңәшем шул:
Сөйгән ярыгыздан көлмәгез.
Җиңел-җилпе чикерткәләр сыман,
Гөлдән-гөлгә кунып йөрмәгез.

**ФАКИЯ ХӘЛИУЛЛИНА**

## ФӘНИДӘ БӘЕТЕ

Чәчем тарадым, никтер үрмәдем,
Бу китүемдә "Сау бул!"- димәдем.
Актык китүем диеп белмәдем,
Бәгърем, мин сезне туя күрмәдем.

Эчләрем пошты, утырып барганда,
Җырлар җырладым сыер сауганда.
Сыерлар савып, фляга тутырдым.
Машиналарга ашыгып утырдым.

Утыргачтын да улый башлады,
Газиз тәнемне турап ташлады.
Акты каннарым,бетте хәлләрем,
Шушы микәнни соңгы мәлләрем.

Күргән дусларым кан-яшь түктеләр,
Башым күтәреп, битемне үптеләр.
Һич тә түзмәслек әрни бит ярам,
Бальнис юлында чыгармы җаным?

Келтер дә келтер бара машина,
Машина җитте минем башыма.
Булган врачлар каршы алдылар,
Ярамны күреп хәйран калдылар.
Яраларымны башта юдылар,
Шуннан соң тизрәк тегеп куйдылар.
Эшләр бетүгә башым әйләнде,
Ушларым китте, телем бәйләнде.
Актык сүземне кемгә әйтәем?
Күрми кала бит газиз әнкәем.
Каты әрнүгә түзмәс йөрәгем,
Тына йөрәгем, әрнеп үләмен.
Күрми калганнар, бәхил булыгыз!
Изге булсын дип,дога кылыгыз.
Каберем өстенә чардуган корыгыз,
Агач утыртып, нурландырыгыз.
Яфраклар ярса, кошлар сайраса,
Рухым шатланыр, догалар барса.

### ЙОСЫП БӘЕТЕ

Йөзеп барганда дулкыннар какты,
Зифа буйларым суларга акты.
Суларга баткач, төпләрен күрдем,
Һич тә чарасыз җанымны бирдем.

Су төбен тырнап бармагым талды,
Газиз әнкәем күрми дә калды.
Суның төпләре караңгы икән ул,
Имезгән сөтеңә, әнкәй, бәхил бул!
Кара костюмым чөйләрдә калды,

Мине язмышым суларга салды.

Һич тә еламый, энкәй, түзмәссең,
Суларга карап мине эзләрсең.
Авылга кайткач, чәчкәләр җыйдым.
Суда йөзәм дип, башымны җуйдым.

Мине энкәем озатып калды,
Зур сулар минем җанымны алды.
Суларга кергәч, әйләнде башым,
Кортлар, балыклар булды юлдашым.

Сулар күп эчтем, эчләрем күпте,
Җаным чыгарга вакытлар җитте:
Бата башлагач, кулымны суздым,
Су төбен күргәч, өметне өздем.

Су читләрендә калды күлмәгем.
Якты дөньяны туя күрмәдем.
Бата башлагач, йомдым күземне,
Әйтә алмадым соңгы сүземне.

Суда үлармен,–диеп үсмәдем,
Әткәй, тиргәмә, юри төшмәдем.
"Балам кайтыр",–дип энкәй көткәндер,
Җыяр ризыгым, ахыры, беткәндер.

## ХӘМИДУЛЛА БАБАЙ МАҖАРАЛАРЫ

Һәр авылның Хуҗа Насретдинга тартым тапкыр, җор телле, шаян кешеләре буладыр ул. Безнең Арслан авылында да бар андыйлар. Хәмидулла бабай –әнә шундый шук кешеләрнең берсе иде.

Хәмидулла бабай карчыгы белән бәләкәй генә өйдә яши. Тышта чатлама суык. Бабай йокыдан тормаган–сәкедә иренеп ята. Әнә карчыгы, мичкә ягар өчен, бер бәйләм салам кертеп ташлады. Азрак булды, ахыры, дип сөйләнә-сөйләнә, яңадан чыгып китте. Хәмидулла бабай барысын күрепишетеп ята иде. Карчыгы чыгып китү белән, ул тиз генә урынынннан торып салам астына керә дә ята. Карчыгының тагын салам күтәреп керүен ишетеп яткан Хәмидулла карт, әкрен генә кыймылдап, өстендәге саламны селкетә, җанландыра башлый. Башта карчыгы телсез калып карап тора да кинәт яман тавыш белән акырып күршеләренә чыгып йөгерә. Ә хәзер Хәмидулла бабай яңадан юрган астына кереп чума.

Менә бераздан күршеләрен ияртеп карчыгы кайтып керә:–Тор әле, тор, салам белән әллә нәрсә күтәреп кергәнмен,–ди ул.–Башта нишләргә белмичә селкенде, аннары озын мөгезен чыгарып сөзәргә килә башлады....

Хәмидулла бабай йөзлек читенә торып утырды:–Мин син кычкыра-кычкыра чыгып йөгергәндә генә уянып киттем,–диде ул, күзләрен угалаган булып.–Чыннан да синең арттан бер мөгезле, озын койрыклы , кап-кара төстәге

нәрсәдер чыгып китте шул.

Болай да коты очкан карчык, ошбу сүзләреннән соң, бөтенләй калтырана башлады.

Шушы хәлдән соң бабайның үзенең дә мәшәкате артты. Карчыгы комган белән чыкканда да аны үзе белән иптәшкә йөртә башлады. Ә салам ягына әйләнеп карарга да курка иде. Хәмидулла бабай шулай да серне ачмады. Үземә-үзем мәшәкать арттырдым, дип елмаеп кына куя иде.

Әйе, мәшәкать артса да, ул барыбер шуклыгын ташламады. Бер елны җәй бик коры килде. Бөтен табигать дымга тилмерә. Көннәрдән бер көнне "Биксел" ягыннан кара болыт күтәрелде. Кинәт кузгалган җил яңгыр исен дә китереп җиткерде.

Бу вакытта Хәмидуллаларда күрше хатыннары чәй эчеп утыра иде. Бабай чабата кайтарып утыра. Менә ул аны калыплап тезә башлады. Чәйләп утырган хатыннар: "Яуса гына ярар иде!"– дип теләк телиләр. Шул чак чытырдатып якында гына күк күкрәде. Табындагылар белгән догаларын укый башладылар. Йа, ходa, бәла-казадан үзең сакла! Менә бер-бер артлы тагын күк күкрәде. Көчле җил белән яңгыр ява башлады. Почмактарак торган Хәмидулла бабай чираттагы күк күкрәгәндә кинәт кенә кулларын бер-беренә каты сугып вә яман тавыш чыгарып идәнгә ауды. Шуннан хатыннар: "Хәмидулла абзыйны яшен сукты",–дип, берсен-берсе тапардай булып чыгып йөгерделәр. Күрше ир-ат "Кинәт килгән яңгыр бер-бер фаҗига алып килә иде ул",–дип Хәмидулланың капка төбенә

җыелды. Нигәдер өй эченә үтмичә, "Мәрхүм кай төшкә ауды икән?" дип тәрәзәдән күз ташладылар. Карасалар, Хәмидулла карт өстәл артында чәй эчеп утыра! Әллә күзгә күренәме бу дип, башта ышанмый торалар, шуннан көлешә-көлешә өйгә керәләр. Хәмидулла бабай, берни булмагандай, аларны чәй эчәргә чакыра. Күршеләре:

–Ничек булды соң, күрше? Хатыннар бит сине яшен сугып үтерде дип кайтып әйттеләр,–дип сораша башладылар. Хәмидулла, елмая биреп:

–Мин үзем дә сукты дип уйлаган идем, күрәсез бит, исән калганмын.

Аның шушы сүзләреннән соң барысы да рәхәтләнеп көлеп җибәрделәр. Менә шундый шук кеше иде мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын!

## ҮГЕЗ КУЛЫ

Арсланнан Урзайбаш авылына бара торган юл өстендә "Үгез кулы" дигән бер урын бар. Картлар сөйләвенчә, әгәр бу урыннан кеше ялгызы гына үтә икән, ул адаша, яисә җен күрә, имеш.Арба яки чана белән үтсәң, убыр уты эт яки чучка кыяфәтендә утырып килә дә юлны ялгыштыра, адаштыра икән.

Бала-чага, яшь–җилкенчәк мондый хәлләргә ышана иде, әлбәттә. Кемдер "Үгез кулы"нда убыр уты күрдем дип икенче берәүгә сөйли, тегесе арттырыбрак өченсенә, тегесе дүртенчесенә сөйли. Безнең авыл укучылары элек, дүртенче сыйныфны тәмамлагач, Урзайбаш мәктәбенә йөриләр иде. Без

һәр көнне шушы "үгез кулы" аша барып-кайтып йөрдек. Сугыш вакытында бик авырга туры килде: өстә сәләмә кием, тамак ач, биш-алты чакырым тегеләй дә, болай да тәпи туратта җилдерәбез. Шулай да үсмер чак үзенекән итә, үз күңелебезне үзебез күрергә тырышабыз, төрле кызыклар уйлап чыгарабыз.

Кырык икенче елның декабре. Әллә каян башка бер "этлек" килде. Каршы күрше-сабакташым Әнәскә:

–Әйдә, бүген укучыларны юлдан кире борабыз,–дидем.

–Ә ничек?–ди бу.

–Беләсең бит инде теге "Үгез кулы"н. Мин шул таңгалгә җитәрәк, иптәшләргә:

"Әнә утлы шар тәгәри",–диярмен. Син: "Әйе шул, әнә, әнә! Мин дә күрәм",–диярсең. Шуннан соң барысы да кире борылачак,–дип ниятемне сөйләп бирдем.

Гадәттәгечә, таң атмас борын бер-бер артлы тезелешеп атлыйбыз. "Үгез кулы" тирәсенә якынлаша башлагач:

–Егетләр,–дим–алда ут күренә түгелме соң?!–Үзем шып туктадым. Азмы–күпме каранып торгач, Әнәс:

–Берәү генә түгел, ике ут әйләнә,–дип өстәде. Ул да булмады, арабызда иң озын буйлы Сабирулла да, озын муенын алга сузып, бераз карап торды да:

–Ике генә түгел, өч ут әйләнә,–дип пышылдады.

Мин эчемнән генә "әһә, Әнәс моңа да әйтеп

куйган икән" дип уйладым. Укучыларның барысы да тукталып бер урында таптанып тора. Шуннан мин Урзайбаш ягына карап:

–Утлар безгә таба килә!–дип кычкырып җибәрдем. Шушы сүзләр барчасын хәрәкәткә китермәсенме! Олыраклар да, бәләкәйләр дә бер-берсе өстенә менәрдәй булып кире йөгерергә тотындылар. Минем көләсем килә, әмма сиздерергә ярамый. Мин дә тегеләр артыннан теркелдәгән булам, үзем: "Мине ташламагыз! Мине ташламагыз!"–дип кычкырам. Ә алар аның саен кызурак чаба. Арып-алҗып, авыл башына кайтып җиттек. Курку басыла төште, үзара сөйләшә башладык. Хәзер мәктәпкә соңга калдык инде, барып тормыйк, дип һәркем өйләренә таралышты. Үзебезнең турга җиткәч, мин Әнәстән:

–Син әллә Сабируллага да серне чиштеңме? Ул бөтенләй арттырып җибәрде,–дип. Ул көлеп җибәрде:

–Курыкканга–куш диләрме әле?! Юк, мин аңа әйтмәгән идем,–диде.

Шулай итеп, "Үгез кулы" тарихына тагын бер сәхифә өстәлде. Ул чакта бергә булган иптәшләр әлеге хәлне бу урынның "җенле" икәненә бер дәлил итеп сөйлиләрдер әле. Шулай да берничә ай үткәч, җай китереп, мин Сабирулладан: "Син чыннан да ут күрдеңме?" дип сорадым. Ул миңа чын күңелдән утның өчәү икәнлеге, бергә уйнаулары турында сөйләде.

**(Фәрит Котыевның хәтер дәфтәреннән).**

## БӨРКЕТЛӘР

Гомуми җыелыш бара. Колхоз рәисе хисап тота. Күп эш башкарылган. Шулаен шулай да, тик бер ел инде колхозчыларның бер тиен дә акча күргәннәре юк. Рәиснең миен бер сорау бораулый: "Ничек шушы хәтәр "шарлавык"ны исән-имин үтеп китәргә?" Кинәт рәиснең башына матур бер фикер килә. Шуннан ул залдагыларга ап-ачык бер сорау ташлый:

–Ничек уйлыйсыз, кошларга акча кирәкме?

Барысы да бертавыштан:

–Юк, кирәкми!–дип кычкыралар.

–Дөрес әйттегез, бөркетләрем!–ди куанычы эченә сыймаган рәис.

## КУЗГАЛАК

Фәрит Габдерәхим бакчадан кузгалак алып керә. Туксанны узган әнисе–Мөэминә әби ашап карарга–зәңгелә качырырга була. Авызында әвәли–әвәли дә болай ди ул:

–Ката башлаган, ахры. Чәйнәем-чәйнәем, һич чәйнәп булмый.

Ә үзенең авызында сыңар теше дә юк.

## ТИРӘН–КҮЛ СУЫ

Автобус тукталышында Фәрухтәй (мәрхүмә инде, авыр туфрагы җиңел булсын!) авылга әнисенең

хәлен белергә кайткан Фәрит Габдерәхимнән:

–Апаем, сине Арсланга бөтенләйгә кайта дигәннәр иде. Шул расмы?–дип сорый.

–Кайтмам, ахры...ди тегесе.

–Нәрсә Уфа җибәрмиме әллә?

–Тирән -кулның сез эчә торган суы ошамый.

Шушы сүзләрдән соң тукталыштагыларның барысы да сәерсенеп Фәриткә карады. Ул әйткән сүзләрен ачыкларга мәҗбүр булды:

–Тирән-кул суын эчәсең, эчәсең–һич туеп булмый. Шул да булдымы су! Ә менә Уфа суын бер стакан гына эчсәң дә җитә, башкача эчәсе килми.

Аңладылар –барысы да берьюлы көлеп җибәрде.

## ПАЙДУШ БАБАЙ

Аңа "Пайдуш абзый", "Пайдуш бабай" диләр. Үзе юк чакта, әлбәттә. Нинди сәер исем бу? Аның үзенә күрә тарихы бар.

Бер урыс Арслан авылыннан үтеп бара икән Пайдуш бабайга очраган. Аңардан:

–Как попасть в деревню Урзайбашево?–дип сораган. Теге өйрәтергә тотынган:

–Минниянский тыкырык, керәеш тә чыгаеш, чожынский багана, бераз баргач–умирал (шушы сүздән соң урысның күзләре шар булган). Патум туп-прәме туп-пайдуш,–дип бик аңлаешлы итеп өйрәткән ди.

Мәгънәсе болайрак була инде: "Минияннар тыкырыгын үткәч, телеграмм баганаларын

күрерсең. Юл зират кырыннан үтә. Әнә шул юл белән туп-туры барасың," янәсе. Менә шуннан соң аңа "Пайдуш" кушаматы ябышып кала да инде.

Бервакыт ул ерак базарга киткән. Юл урыс авылы аша уза. Урамда берәү:"Куда идешь?" дип сорый моңардан. Бу сүз аңа "куда пайдуш?" булып ишетелгән. "Бәрәкалла, мине монда да беләләр икән!"-дигән эченнән генә, канәгатьләнү белән. Ә чын исеме Габдерәхим иде мәрхүмнең.

## ТӨРЕПКӘ САБИРҖАН

Сабирҗан абзый кара-тут йөзле, чандыр гәүдәле кеше иде. Авызында һәрвакыт төрепкә. Бригадир чагы моның. Бер көнне Корбанай урманы буендагы басуга колхозчылар янына киткән. Барып җитәрәк тартасы килә башлаган моның. Кесәләрен караштыра-төрепкә юк. Өйдә торып калган, шайтан алгыры! Сабирҗан абзый атын кире бора. Ихатага килеп керү белән хатынына:

-Мөслимә, төрепкә торып калган бит, алып чык тизрәк!-дип әйтергә авызын гына ачкан, авызындагы төрепкәсе җиргә килеп тә төшкән.

## ШӘРӘФИ АБЗЫЙ

Шәрәфи абзый урамда бригадир Сәяхне очратып:

-Энем, сине күптән чәйгә чакырырга йөрим, һич җае чыкмый,-ди.-Бүген кичке якта безгә кереп чык әле.

Сәях яхшы белә–"чәй" дигәннәре "мәй" була инде ул. Иртәдән бирле тамагы кымырҗып тора иде, юкка түгел икән.

Түземсезлек белән көтеп алынган кич тә килеп җитте.

–Әйдүк, энекәш, түрдән!

Өстәлдә зур җиз самовар җырлап утыра. Шәрәфи абзый чәйне үзе ясады.

–Җитеш, туган! Ай, әттәгенәсе, кәнфитне оныткандбыз бит. Алып кер тизрәк, карчык!

–Карчыгы чоланнан зур булмаган касә тотып керде. Аның төбендә кәгазьсез, түгәрәк биш-алты конфет ята иде.

–Сәях энем, үзеңә ошаган конфетны сайлап ал!–дип әлеге касәне Сәях алдына этәрде Шәрәфи абзый.

Шулай итеп, бригадирыбыз, бер конфетны суыра-суыра, гомерендә беренче тапкыр "мәйсез" чәй эчеп чыгып китте.

Шәрәфи абзый беркайчан да башкаларны узып алга чәчрәп чыкмас, ашыкмас-кабаланмас. Язгы чәчү вакыты иде. Биш-алты тырмачы малай төшке кыләмгә кайтып бара. Араларында берданбер олы кеше–Шәрәфи абзый. Авылга ике чакрымлап бар. Кинәт югары очта утлы төтен баганасы күтәрелә башлады.

–Пожар!

Малайлар арык атларын ашыктыра башлаганнар иде, Шәрәфи абзый:

–Ашыкмагыз, малайлар! –дип тегеләрне

тыйды.–Атлар бик йончыган бит.Аннары ут сүндерү җиңел эш түгел, анда эт кебек арыйсың.

Менә алар "Песи күпере" үренә дә күтәрелделәр. Хәзер югары оч ап-ачык күренә.

–Шәрәфи абзый, ут сезнең ихатада түгелме соң?!

Үзенең янганын Шәрәфи абзый да күргән иде инде.

–Малайлар!–дип кычкырып җибәрде ул ялварулы тавыш белән.–Янам бит, янам! Чаптырыгыз инде атларыгызны!

## ТАТАРЧА ӨЙРӘНСЕН

Фәрит Габдерәхимнең сигез яшьлек оныгы Марат Уфада яши. Җәй көне картәтисе аны авылга алып кайтты. Иркендә йөрсен, саф һава суласын, чиста су эчсен. Иң мәһиме, әз булса да татарча өйрәнсен. Якын-тирә күршеләрдә үзе кебек малайлар байтак. Әнә шулар "өере"нә кертеп җибәрде оныгын.

Марат бер айга якын рәхәт чикте: шул малайлардан аерылмады, ашарга да, хәтта йокларга да кайтып кермәде.Кире Уфага киткәндә оныгының татарчасы элекке хәлендә иде. Аның каравы, күрше малайлар урысча элеккедән остарак сөйләшә башлаганнар иде.

**(Фәрит Габдерәхимнең хәтер дәфтәреннән).**

## ТАГЫН ҖИДЕ МИНУТ БАР

Үзен нык карый торган теге абзыйга (исемен әйтүнең кирәге юк: сез кем турында сүз барганын болай да яхшы беләсез) балалары, туган-тумачалары, кунаклар җыелган. Табын әзер, кунаклар утырышкан.

–Әйдә, үзең дә утыр инде,–диләр табындагылар.

Теге сәгатенә карап ала да:

–Минем ашый торган вакыт җитмәгән, тагын җиде минут бар әле"–дигән.

**(Габделхәй Садыйковның хәтер дәфтәреннән).**

## "НИТ"

Җиләк уңган бер җәйне Миңнеямал әби белән Галия әби Кандра базарына җиләк сатарга киткәннәр. Шулай ару гына җиләк сатып утырган чагында болар янына бер урыс килеп: "Почем ягоды?!–дип сораган. Урыска белмәгән карчыклар сүзнең нәрсә турында барганын да аңламаганнар. Миңлеямал карчыкның урысча бөтен белгән сүзе "нет" булган. Ул урыска "нит"! дип кенә кычкырган. Урыс, әлбәттә, сүз куертуның файдасыз икәнен аңлап, шунда ук китеп барган.

Авылга кайткач, Миңеямал карчык болай дип сөйли икән:

–Галия карчык, җебегән, бер сүз дә әйтәлми тора. Урыска бер генә аяк тибеп "Нит!" дип кычкырдым, урыс китте дә барды.

## ЯЛКАУ ВӘЛИ

Авылда ялкау Вәли дигән бер кеше Богадыга йомыш белән барган да кайтышлый "Турҗы тавы"нда ике кич кунган ди, җәяү кайтырга иренеп. Шуннан өченче көнне Абдулла абыйның велосипеды артына утырып кына авылга кайтып җиткән ди.

**(Рамил Азаматовның хәтер дәфтәреннән).**

## БЕР МЕҢГӘ ГЕНӘ ЯЗ ИНДЕ

Безнең авылда акча исәбен белми торган Минниямал әби бар иде. Шулай, сугыш вакытында заемга язып йөриләр. Район үзәгеннән килгән вәкил:

–Әбекәй, сиңа өч йөз сум язарга булдык,–дигән.

–И, палнамуч апыкаем, зинһар, бер меңгә генә яз инде,–дип әйткән ди Миннеямал әби.

**(Сәмәрә Камаеваның хәтер дәфтәреннән).**

# Әкиятләр

# АРСЛАН

Борын заманда безнең авыл тирәләрендә үтеп чыккысыз кара урман булган. Авыл дигәч тә, авыл үзе булмаган әле. Бердәнбер көнне ерак-ераклардан бу якларга аучы егет килеп чыккан. Урман төрле җәнлек вә кош-кортка ифрат бай. Егеткә ошаган бу төбәк. Инеш буендагы уңайлы бер урынга ул йорт, мунча салып җибәргән ди. Көн дә тозак-капкыннарын тикшерергә чыгып китә бу. Бер дә буш кул белән кайтмый. Аның җитез угыннан куяны да, төлкесе дә,бүресе дә, башкасы да качып котыла алмый.

Көн артыннан көн, ай артыннан ай үтә.Арслан исемле теге егет иртән чыгып китә дә кичен генә кайтып керә.Ә менә бер көнне кайтып керсә...Егетебез шаклар ката:өй җыештырылган, мич ягылган.Өй эченә бәлеш исе таралган.Мич эченә күз ташласа–бәлеш! Хәйран хәлләр! Аучы халкы тәвәккәл бит инде. Арслан теге бәлешне тартып чыгара да ашарга тотына. Куян итеннән пешерелгән бәлеш телеңне йотарлык ди.

Арслан икенче көнне дә гадәттәгечә ауга чыгып киткән. Кичен кайтса–тагын шул ук хәл кабатланган–мичтә бәлеш көтеп тора ди. Бу хәл тагын, тагын кабатланган. Егетебез чиксез аптырашта.Якын-ерак җирләрдә адәм заты юк ләбаса. Шуннан Арслан хәйлә кора. Иртән ау коралларын күтәреп чыгып китә дә, күпмедер вакыт үткәч, качып-босып кире әйләнеп кайта һәм тәрәзә читеннән генә өй эченә күз сала. Йа хода! Өйдә

озын толымлы, яшь, искиткеч чибәр бер кыз мичкә бәлеш тыгып маташа ди.Озак уйлап тормастан, егетебез өйгә ялт итеп килеп тә керә.Билгеле,кыз моны көтмәгән була. Йөзен куллары белән каплап читкә борыла.Арслан көчле куллары белән кызны кочып-күтәреп ала. Егет гашыйк була:

–Миңа кияүгә чык!–ди.

–Мин риза,–ди кыз. –Тик бер шартым бар...

–Тизрәк әйт шартыңны!–ди түземлеге калмаган егет.

–Икебез бергә мунча кермәскә тиешбез.

Арслан риза, әлбәттә. Шулай итеп, алар бергә яши башлыйлар.Бер-бер артлы уллары туа. Әмма күпме бергә яшәсәләр дә, мунчаны аерым керә болар. "Нигә аерым керә соң ул?" Менә шушы сорау тынычлык бирми Арсланга. Нәрсәдә икән моның сере? Хатыны мунчага китеп күпмедер вакыт үткәч, Арслан тегенең янына бара да керә ди. Ни күрсен! Хатыны озын толымлы чәчен баш түбәсеннән куптарып алып алдына салган да бет карап-эзләп утыра ди. Хатыны чәрелдәп кычкырып җибәргән:

–Нигә кердең? Нигә сүзеңдә тормадың? Мин бит җен кызы. Адәми зат чәчемне кубарып алган чагымны күрергә тиеш түгел иде,–дигән дә җан биргән ди.

Шулай итеп, Арслан уллары белән генә торып кала. Үсеп җиткәч, алар әтиләре янында йорт салып яши башлаганнар ди. Үз чиратларында аларның да балалары йорт салып башка чыкканнар.

Әнә шулай авыл барлыкка килгән. Аны беренче булып нигез корган Арслан исеме белән атап йөртә башлаганнар ди.

**(Фәрит Габдерәхимнең хәтер дәфтәреннән).**

## БАШ БАТЫР

Борын-борын заманда шомырт агачлары арасында утырган бер авылда яшәгән ди бер ир белән бер хатын. Ни сәбәптәндер бу гаиләнең туган бер баласы үлә барган. Бишенче малайларын җирләгәч, ир белән хатын бик кайгырып утырганнар, Ходайдан ялварганнар гомерле бала бүләк итчәле дип. Менә, ниһаять, теләкләре кабул булып, боларның тагы да бер малайлары туа. Малайга Ягъфәр исемен кушалар. Ягъфәр бик ябык, бик зәгыйфь була. Яшьтәшләреннән нык калыша. Иптәшләре һәр көнне аны кыйнап, елатып кертә торган булганнар. Ягъфәр кич йокыга ятканда иптәшләренә бик рәнҗеп, күз яшьләре белән йоклап китә һәм мәзәк бер төш күрә. Ачык тәрәзәдән ап-ак күгәрчен очып керә дә Ягъфәрнең күкрәгенә бер бөртек бодай куя һәм телгә килеп: "Иртән торгач та шушы бодайны салкын суга салып йот. Шуннан синдә чикләнмәгән көч барлыкка килер",–дип әйтә дә очып китә. Ягъфәр тиз генә урыныннан торып ак күгәрчен әйткәннәрнең барын да эшли. Үзенең гәүдәсенең зураюын, көч-куәтенең артканнан-арта баруын тоя.Моңа кадәр киеп йөргән киемнәре хәзер ярамый. Ул әтисенең киемен киеп,

кулына балта алып, сиздерми генә өйдән чыгып китә. Урманга җиткәч, күгәрчен әйткән сүзне сынап карарга була. Балтасы белән юан агачка китереп чабуы була, агач киселеп чыга һәм гөрселдәп ава. Шуннан соң үсеп утырган имәнне төбе-тамыры белән тартып чыгара. Ягъфәрнең үз-үзенә ышанычы арта. Ул күгәрченгә рәхмәт укып, күкрәген киереп бер киерелеп ала. Әтисенең киемнәре күп урыннан сүтелеп китә. Ягъфәр үзен иң көчле кеше итеп хис итә һәм үзе суырып чыгарган имәнгә башын куеп йоклап китә.

Төшендә теге күгәрчен тагы да килеп Ягъфәрне үзенең көчен беркайчан да усал ният белән кулланмау, начарлык кылмау турында кисәтә. Уянгач Ягъфәр бераз уйланып утыра да юл буйлап китеп бара. Күп тә үтми, ул бер авылга килеп чыга. Кешеләр җыелып тегермән ташын алыштырырга җайланма корып яталар. Ягъфәр, сәлам биреп, тукталып кала. Ир-атлар галәмәт зур ташны төрле җайланмалар белән әкрен-әкрен генә тегермән янына китерәләр. Ирләр маңгай тирләрен сөртеп ял итәргә туктаган арада Ягъфәр бу ташны кай төшкә куярга җыенуларын сорый. Менә шушында торырга тиеш ул, улым, дип тегермәнче ташның урынын күрсәтә. Менә Ягъфәр җиңен сызганып куя, ирләрнең мыскыллы карашлары астында тегермәннең аскы ташын, күкрәгенә күтәреп, урынына илтеп сала. Кешеләр беравык телсез калып торалар, аннары дәррәү Ягъфәрне уратып алалар, сораша башлыйлар. Ләкин Ягъфәр үзенең

исемен генә әйтә дә: "Мине көтәләр,хуш, сау булыгыз!,–дип китеп бара. Шушы көннән башлап Ягъфәр төрле авылларда, шәһәрләрдә булып үзенең көчен кешеләргә ярдәм итүдә кулланып зур дан казана. Аның кылган игелекләрен һәр урында тагын да арттырыбрак сөйлиләр. "Их, шул егетне күзнең кырые белән генә булса да күрәсе иде!"–дип хыялланалар.

Менә ул зур бер акланга килеп чыга. Аклан уртасында бәйрәмчә киенгән йөзләрчә кеше. Егетебез бераз карап тора да эре-эре атлап чирәмдә утырган кешеләр янына килә. Баш иеп сәлам бирә дә: "Бу нинди бәйрәм?"–дип сорый. "Син чит кеше буласыңдыр, әгәр мондагы кеше булсаң, белер идең. Без менә өченче көн инде Сабантуй батырын ачыклый алмыйбыз. Ике батыр өч көн буена бер-берсен җиңә алмыйлар. Ә җиңгән батырга авылыбызның иң чибәр кызы Зөбәрҗәт үз кулы белән чиккән ак күлмәк бүләк итәргә вәгъдә бирде, диләр. Ягъфәр батырлар белән алышырга теләк белдерә. Мәйданга яшен тизлегендә тарала бу хәбәр. Көрәш мәйданына барлык кеше җыела, һәркем яңа батырны күрергә тели. Ягъфәргә ике батыр белән берьюлы көрәшәчәген әйтәләр, һәм ул риза була. Менә мәйданда тынлык урнаша, барысы да ни булыр икән дип көтә башлый. Ягъфәр каршына берсеннән-берсе чибәр, таза ике егет килеп баса. Менә шунда Ягъфәр егетләрнең билбауларыннан эләктереп ала да икесен берьюлы югары күтәреп, биш мәртәбә әйләндерә һәм зур

саклык белән икесен дә яшел чирәмгә аркалары белән сала да бераз тотып тора. Мәйдан башта өнсез-тынсыз кала, аннан көчле алкышлар белән Ягъфәрне котлау яңгырый. Озак та үтми, шундый ук көчле алкышлар астында, Зөбәрҗәт Ягъфәрнең алдына килеп баса һәм матур итеп чигелгән күлмәкне үз кулы белән кидерә. Ул Ягъфәрнең чибәрлегенә хәйран кала, үзләренә кунакка чакыра. Ягъфәрне дә кызның чибәрлеге, тавышының искиткеч ягымлылыгы әсир итә.

Менә Зөбәрҗәтләрнең йорты.Күркәмлеге белән күзләрнең явын алып тора. Әтисе Хәмзә байга батыр турында хәбәр алдан килгән булса да, ул аны ишек алдына чыгып сорау белән каршы ала: "Син, яшь егет, кайдан буласың, әти-әниең бармы?" Тиешле җавап биргәч, Ягъфәр Зөбәрҗәт белән өйгә уза һәм, хуҗаларга хәерле-имин тормыш теләгәннән соң, үзенең Зөбәрҗәткә өйләнергә теләвен әйтә, ризалыкларын сорый. Хәмзә бай башта кызына сораулы караш ташлый, аның ризалыгын аңлагач, тамак кырып куя да: "Ярый алайса, мин риза, тик бер шартым бар,-ди.-Менә безнең авыл кырында зур бер таш бар, ул елганы ике якка бүлеп тора, шуны моннан егерме чакрымдагы кургыга илтеп ташла". Ягъфәр Зөбәрҗәт белән баш иеп хушлаша да таш янына килә. Таш бик зур һәм авыр була. Караңгы төшкәнче таш кырында утыра егет. Караңгы төшү белән, тәгәрәтеп Хәмзә бай әйткән кургыга илтеп сала һәм кире кайтып Хәмзә байга шартның

үтәлүен әйтә. Барып карасалар–таш урынында күл хасыйл булган. Хәмзә байга кызын бирүдән башка чара калмый. Бер айдан килеп алырга вәгъдәләшеп, Ягъфәр туган авылына кайтырга чыга. Зөбәрҗәт күз яшьләрен сөртә-сөртә аны озатып кала.

Ягъфәр юл уңаенда теге кургыга килеп чыга. Анда бик күп халык җыелган. Кургыда таныш таш су чыга торган урынны каплаган, елга корыган. Кешеләр, суга интегеп, бу ташны көн дә килеп ваталар икән. Йөзләгән кеше лом, кәйлә белән ташны ватарга маташуларын карап тора да алардан сорый: "Башкача инеш юкмыни?" Шуннан зар елап җавап биргән кешеләргә: "Барыгыз да яр башына бер якка менегез!"–ди. Һәммә кеше, ни булыр икән дип, кургы өстенә күтәрелә. Ягъфәр ташны көчле кулбашы белән этә башлый. Таш чокыр буйлап тәгәрәп китә, һәм киңрәк урынга җиткәч, Ягъфәр ташны бер як ярга этеп чыгара.

Менә башта таш урынында су күренә, ул күбәйгәннән-күбәеп ага башлый. Ягъфәрнең һәр хәрәкәтен күзәтеп торган кешеләр егетне кочаклап алалар, рәхмәт яудыралар. Бу арада инде таш урыныннан ургылып су элекке эзе белән ага башлый.

Ягъфәр туган авылына кайтып җитә, ниһаять. Башта аны танымый торалар. Әти-әнисе дә, аны күптән үлгәндер инде дип, өметләрен өзгән булганнар. Ниндидер пәһлеванның изге эшләре турындагы хәбәр авылга килеп җиткән булса да,

беркем дә аны Ягъфәр дип башларына да китерми.

Озакламый Ягъфәр белән Зөбәрҗәтнең туйлары була. Тирә-яктан күпләр килеп аны котлыйлар, рәхмәтләрен белдерәләр. Үзенең көчен ул гомер буе кешеләргә бәхет китерүгә багышлый, бервакытта да усал ниятә файдаланмый.

Алар Зөбәрҗәт белән тату яшәп өч кыз, өч ир бала үстерәләр. Ягъфәр Арслан авылына да килеп киткән, имеш. Инеш башындагы зирек агачын төбе белән йолкып су чыганагы тапкан ди. Ул инеш әле дә авыл халкына игелек күрсәтеп агып ята ди.

**(Фәрит Котыевның хәтер дәфтәреннән).**

## ГАЗЕТА УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ

**Хөрмәтле редакция!**

**Мин сезгә үзем язган берничә шигыремне җибәрәм. Туган авылыма булган мәхәббәтемне сезнең газета аша үземнең авылдашларыма җиткерергә телим. Мин Әмир авылында туып үстем. Хәзерге вакытта Арслан авылында яшим. Шигырьләрем газетада басылса, шат булыр идем. Мин гади колхозчы гына, укымышым түбән, ошамаган җирләрен төзәтсәгез дә үпкәләмим.**

**Суфия ГЫЙЛАҖЕВА, Арслан авылы.**

**Редакциядән: Яшерен-батырын түгел, редакциягә килгән "иҗат җимешләре"нең төрлесе була. Аз-маз үзгәртү белән генә чикләнмичә, кайберләрен, кем әйтмешли, астын–өскә китерергә мәҗбүрбез. Ә бу шигырьләр– күңелле һәм сирәк искәрмә– берничнди үзгәрешсез бирәбез.**

### САГЫНАМ СИНЕ, КӨЯЗЕМ!

Кайтыр идем туган авылыма,
Ялбыр чәчле нәни кыз булып.
Кайтыр идем очып, канатланып,
Байдашкаем, сине сагынып.

Кайтыр идем дус кызларым белән
Хәтфә үләннәрдә уйнарга.
Матур күлмәк киеп, ялан тәпи
Барыр идем сабантуйларга.

Дөнья киң бит, елгалар да бик күп,
Иң матуры– минем Көязем.
Ярларына үскән талкайларны
Их, күрәсем килә, күрәсем!

Көязекәй, һаман син матурмы?
Камышлар да шаулап торамы?
Ярларыңда үскән тирәкләрдә
Сандугачлар оя корамы?

Көязекәй, синең аръягыңда
Бар иде бит куе әрәмә.
Какы, кузгалаклар күкрәп үсә,
Шомырт, балан кая карама.

Туган авылымда гына шундый
гүзәл,
Шау чәчкәле, иркен тугайлар.
Зәңгәр күктә, көмеш моңнар сибеп,
Җырлашалар сабан тургайлар.

Еллар үтте, байтак сулар акты,
Артта калды гүзәл балачак.
Балачактан калган хәтирәләр
Гомер буе озата барачак.

Һәрчак сагынып Әмиремә киләм,
Каршы ала мине Көязем.
Ул саеккан, камышлары кипкән,
Ник картайдың?–килә диясем.

Гүя телгә килә Көязекәй:
"Әрәмәмне харап иттеләр.
Көтү йөргәч, талларым да кипте,
Кошларым да ташлап киттеләр.

Таллар кипкәч, камыш тибрәлмәгәч,
Дәрман юк шул көмеш суыма.
Күптән инде килми шат балалар,
Каз–үрдәкләр генә коена...

Авылдашлар, мине кичерегез,
Язганнарым ялган тоелса.
Гаҗәпмени Галим күле бетеп,
Байдаш суы кибеп корыса.

Гаҗәпмени колхоз көтүләре
Әрәмәне таптап йөрсәләр.
Зифа таллар әрнеп, үксеп елап,
Башкайларын түбән исәләр.

Кичерегез мине, авылдашлар,
Тормыш ага үзенең эзеннән.
Балачакның сихри кузлегеннән
Барысы да гүзәл күренгән.

Әрәмәкәй беткәч, тау битенә
Утырткансыз зифа каеннар.
Тирә-якны яшеллеккә күмеп,
Һәр яз саен яфрак ярырлар.

Туган авылым минем, Әмирем,
Гел килермен сине сагынып.
Шул каеннар мине сәламләрләр,
Яшел чуклы шәлләр ябынып.

### ТАРАТМАГЫЗ АТА НИГЕЗЕН

Әнкәемнең кулы кабызган
Учаклар да янып сүрелгән.
Тал читәннәр инде юкка чыккан
Әткәм кулы белән үрелгән.

Без дөньяга килгән ихатага
Ятлар инде хуҗа булганнар.
Без аунаган бәбкә үләннәр дә
Күптән инде кибеп сулганнар.

Күршеләр дә хәзер икенчеләр,
Аңламаслар кебек күңелне.
Көләч Бибикамал апа, Хәнифәттәй,
Әминәттәй күптән юк инде.

Гел барасым килә авылыма,
Ул бит минем күңелем көзгесе.
Арыганда килеп хәл җыярга
Юк шул инде әткәм нигезе.

Сагынам шул сине, Түбән очым,
Яшел хәтфә кебек чирәмең.
Йөрәгемә шифа булыр кебек
Һәр үләне шуышы тирәнең.